**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**8 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган республика олимпиадасының**
**муниципаль этабы өчен биремнәр**
**(2014/2015 нче уку елы)**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. [*У*] сузыгына дөрес билгеләмәне табыгыз.
   а) арткы рәт, иренләшкән, озын сузык аваз;
   ә) калын, иренләшмәгән, кыска сузык аваз;
   б) нечкә, иренләшкән, озын сузык аваз;
   в) алгы рәт, иренләшкән, кыска сузык аваз.

2. Басым соңгы иҗеккә төшми торган сүзләр рәтен күрсәтегез.
   а) андый, ләкин, кайсы, кешечә;
   ә) унынчы, килсә, алачык, сәбәпче;
   б) кайтты, тәрәзәләр, гөлбакча, унсигез;
   в) эшләдек, уйнаганнар, дәреслек, акыллы.

3. Фонетик принципка нигезләнеп язылган сүзләр рәтен билгеләгез.
   а) алдынгы, манган, төнбоек;
   ә) чәчәкләр, кырдагы, үсемлек;
   б) печәнлек, китабым, болытлы;
   в) әнкәй, борылмалы, төзелеш.

4. Татар телендә ничә авазның үзенә генә билгеләнгән хәрефләре юк?
   а) 3;
   ә) 5;
   б) 6;
   в) 4

5. *Бабамның әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә саклана* җөмләсендә бабамның сүзенең лексик мәгънәсен күрсәтегез.
   а) җөмләдә аергыч булып килгән;
   ә) тамыр һәм бәйләгеч кушмчалардан тора;
   б) өлкән яшьтәге ир кеше;
   в) уртаклык исем, иялек килешендә, I зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән.

6. *Менә барвакыт Сабантуй җитте* җөмләсендә Сабантуй сүзе кулланылыш өлкәсе ягыннан ...
   а) гомумхалык сүзе;
   ә) диалекталь сүз;
   б) һөнәрчелек сүзе;
   в) термин

7. *Серкәсе су күтәрмәү* фразеологизмының мәгънәсе ...
   а) игътибарсыз булу;
   ә) ачулану;
   б) үпкәчән булу;
   в) тату, дус булмау.

8. Билгеләнгән сүзләргә нинди билгеләмә туры килә?

*Туңа-туңа ашадык без*
*Ширбәт салган зур* ***карбызны.***
*Җәй буена ничек кояш*
*Эретмәгән бу* ***кар, бозны***. (Ш.Галиев)

а) омофон;
ә) пароним;
б) омограф;
в) омоформа.

9. Фигыль ясагыч кушымчалар булган рәтне күрсәтегез.

а) -ла/-лә, -ай/-әй, -а/-ә;
ә) -лы/-ле, -чан/-чән, -гы/-ге;
б) -лап/-ләп, -ча/-чә, -ып/-еп;
в) -гыч/-геч, -чы/-че, -ма/-мә.

10. Бәйләгеч кушымчалары булган сүзләр рәтен күрсәтегез.

а) биегрәк, алды, җиденче;
ә) күрделәр, иптәшемнән, йөгереп;
б) эшчәнлек, тимерче, аваздаш;
в) дускай, алтышар, китаплар.

11. *Эчтән, башта, яттан, бергә* сүзләренең ясалу ысулы ...

а) ясагыч кушымча ялгау;
ә) аваз составын үзгәртү;
б) бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчү;
в) сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү.

12. Җөмләдә ясалма нигезле сүзләр ничә?

*Ут-кызыл тәлгәшле миләшнең телем-телем яфраклары, җимешләре белән ярышкандай, кучкылланып кызарганнар*. (Р.Төхвәтуллин)

а) 6;
ә) 5;
б) 7;
в) 4.

13. Хәзерге заман сыйфат фигыльнең тезмә формасы ...

а) үтәлми торган эшне;
ә) кайвакыт үтәлә торган эшне;
б) даими үтәлә торган эшне;
в) үткән заманда эшләнгән эшне билге итеп белдерә.

14. Татар телендә рәвешләрнең ...

а) берсе дә исемләшми;
ә) ачыклаган исеме төшеп калганда, кайбер рәвешләр исемләшә;
б) барлык рәвешләр дә исемләшә;
в) раслауларның берсе дә дөрес түгел.

15. Хәбәрлек сүзләр җөмлә кисәкләре ...

а) була;
ә) булмый;
б) кайвакыт була;
в) дөрес җавап юк.

16. Сул яктагы сүзләр рәте каршысына уң яктан тиешле сүз төркемнәре исемнәренең номерын куегыз.

| | | |
|---|---|---|
| а) дөм, җете, ич, -сана/-сәнә; | | 1. Бәйлекләр |
| ә) кыйгак, дөп-дөп, җем-җем, шап-шоп; | | 2. Ымлыклар. |
| б) дөгә-дөгә, маһ-маһ, ах, урра; | | 3. Аваз ияртемнәре |
| в) чөнки, ләкин, гәрчә, гүя. | | 4. Теркәгечләр. |
| | | 5. Кисәкчәләр. |

17. *Шул вакытта* ***кешеләрнең*** *шатлануын күрсәгез сез*! (И.Гази) җөмләсендә билгеләнгән сүз -

а) аергыч;
ә) тәмамлык;
б) аныклагыч;
в) хәл.

18. Җөмләгә тулы билгеләмә дөрес бирелгән вариантны күрсәтегез.
*Минем телем дә, каләмем дә гомерем буе сезнең кануннарыгызга итагатьле булып калыр*. (Л.Шагыйрьҗан)

а) гади, ике составлы, җәенке, тулы, раслау, тиңдәш кисәкле хикәя җөмлә;
ә) гади, бер составлы, җәенке, ким, раслау, тиңдәш кисәкле хикәя җөмлә;
б) гади, ике составлы, җыйнак, тулы, инкарь, тиңдәш кисәкле боеру җөмлә;
в) гади, бер составлы, җәенке, ким, инкарь, тиңдәш кисәксез җөмлә.

19. Теркәгечләр белән килгән аныклагычлар алдыннан нинди тыныш билгесе куела?

а) сызык;
ә) ике нокта;
б) тыныш билгесе куелмый;
в) өтер.

20. Хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләр кайсы рәттә?

а) музыка аныкы, китап укыла, хат сиңа;
ә) җырланган җыр, укыла торган хикәя, аңа әйтү;
б) килгәч сөйләшү, укып бетерү, шәһәрдә яшәү;
в) шатлыктан елмаю, җем-җем итү, эти белән күрешү.

## II. Теоретик бирем
## Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерүнең 3 очрагы.

**III. Күп ноктalar урынына тиешле сүзләрне куегыз.**

1. Авазларның дөрес әйтелешен тел белеменең ... бүлеге билгели. 2. Татар телендә ... иҗек калыбы бар. 3. Сингармонизмның ирен гармониясе беренче иҗектәге ... ... сузыкларына бәйле. 4. Ясагыч кушымчалы, кушма, парлы, тезмә сүзләр ... нигезле сүзләргә керәләр. 5. Фигыль белән белдерелгән кисәкне ачыклап килгән иялек килешендәге исем җөмләдә ... була. 6. Туры тәмамлык ... һәм ... килешендә килгән исемнәр белән белдерелә. 7. Иясе дә, хәбәре дә булган җөмлә ... ... җөмлә дип атала. 8. Иясе булмаган бер составлы җөмлә ... җөмлә була 9. Әйтелгән фикерне аңлау өчен кирәкле барлык кисәкләре булган җөмлә ... җөмлә дип атала. 10. Бер хәбәрлеге булган җөмлә ... җөмлә була.

## IV. Гамәли бирем.

*Мин җырымның һәрбер сүзенә ачык буяу һәм тавыш яктылыгы бирергә тырыштым.* (Г.Кутуй).

1. Җөмләгә **тулы** билгеләмә бирергә.
2. Тыныш билгеләрен аңлатырга.
3. Җөмлә кисәкләре буенча (асларына сызып) тикшерергә.
4. *Тавыш* сүзенә фонетик анализ ясарга.
5. *Һәрбер, җырымның, тырыштым* сүзләренә морфологик анализ ясарга.
6. *Яктылыгын* сүзен төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерергә.